**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ АЕШ АВЫЛ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
**423741, Аеш авылы,**
**Ленин ур.,34б нче йорт.**
**Тел/факс 3-44-41**
**e–mail: aish-akt.galeeva@yandex.ru**

**АИШЕВСКИЙ СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**АКТАНЫШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
**423741, село Аишево,**
**ул.Ленина, дом 34б.**
**Тел/факс 3-44-41**
**e–mail: aish-akt.galeeva@yandex.ru**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«17» июня 2025 года № 12

**Актаныш муниципаль районы Аеш авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Аеш авыл җирлеге хезмәткәрләренең эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләрен раслау турында» 2023 елның 16 февралендәге 7 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 30 апрелендәге 116-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 05 декабрендәге 498-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе дәүләт хезмәте системасы һәм Россия Федерациясенең аерым закон актлары турында «Федераль законның 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 12 декабрендәге 594-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 16 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2024 елның 30 сентябрендәге 338-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Актаныш районы прокуроры вазыйфаларын башкаручының 2025 елның 03 июнендәге 02-08-02-2025/Прдп 182-25-20920005 номерлы протестын карап, Актаныш муниципаль районы Аеш авыл җирлеге Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Актаныш муниципаль районы Аеш авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Аеш авыл башкарма комитеты хезмәткәрләренең эчке хезмәт тәртибе Кагыйдәләрен раслау

турында» 2023 елның 14 февралендәге  5 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.1. 2.4 пунктта:**

**а) 2 пунктчаны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15_2 статьясында каралган анкета;

**б) 4 пунктчаны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

4) хезмәт кенәгәсен һәм (яисә) хезмәт эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән белешмәләрне, хезмәт шартнамәсе (контракты) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш; (Федераль законның 31.07.2020 № 268-ФЗ редакциясендә)

**в) 5 пунктчаны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

5) мәгариф һәм квалификация турында документ;»

**д) 14** абзацта «белешмәләр» сүзләреннән соң «(анкетадагы белешмәләрдән тыш)» сүзләрен өстәргә,

**1.2 2.14 пунктта :**

**а) 4 абзацны** үз көчен югалткан дип танырга.

**б) түбәндәге эчтәлекле  абзац** өстәргә:

«- муниципаль хезмәткәрләргә чит ил агенты статусын алу».

**1.3 4.2 пунктына** түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«- яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15.2 статьясында каралган анкетада булган белешмәләрнең мәгълүм үзгәрешләре турында язма формада хәбәр итәргә, моңа яллаучының (эш бирүченең) вәкиле карары буенча үзгәргән белешмәләр керми (алга таба - анкетадагы белешмәләр).

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе Д.Р.Ахатов